**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Сапеевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Школьная . 53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района, 423326
Тел. 8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитеты**

Мәктәп урамы, 53В, Сәпәй авылы
Азнакай муниципаль районы, 423326
Тел.8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«21» октябрь 2019 ел

КАРАР
№ 12

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 30.01.2019 ел №1 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» 26.07.2009 ел №226-ФЗ Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16.1 статьясы, «Федераль мәгълүмати адреслы система турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 26.07.2019 ел №227-ФЗ нигезендә Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 30.01.2019 ел №1 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.12. Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты: ышанычнамә таныклыгы (№12 кушымта);».

1.2. түбәндәге эчтәлекле 1.15 пункт белән тулыландырырга:

«1.15. Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читләштерүгә, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (№15 кушымта).»

1.3. Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 1.5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты – капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;».

1.4. 12 нче кушымтаны әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.5. 2 нче кушымта нигезендә кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http/ / aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Ф.Г.Галиева